СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

12.04.2024 Баулы шәһәре № 247

Баулы муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2018 елның 3 июлендәге 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы

Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 159 номерлы «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» (Баулы муниципаль район Советының 2019 елның 25 февралендәге 196 номерлы, 2020 елның 29 маендагы 264 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 16 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге 36 номерлы, 2022 елның 18 августындагы 122 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 161 номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 174 номерлы, 2023 елның 14 августындагы 211 номерлы, 2023 елның 30 ноябрендәге 228 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

14 статьяның 1 пунктын 12) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«12) әлеге Нигезләмәнең 18.2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларга билгеле булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба-анкетада булган мәгълүмат).»;

15 статьяның 1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) ул үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын

биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар бирмәүче, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында шаһитлык бирүче;»;

18.2. статьясы белән түбәндәге эчтәлектә:

«18.2. Анкетаны тәкъдим итү, анкетада булган мәгълүматны үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүматны тикшерү

18.2.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тәкъдим итә.

18.2.2. Муниципаль хезмәткәр яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

18.2.3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

18.2.4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү Баулы муниципаль район Советы Аппаратының кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша да, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Җәмәгать хакимияте органнары һәм тиешле мәгълүматка ия булган оешмалар соралган мәгълүматны әлеге сорауны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

19 статьяда :

3 пунктның  2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Нигезләмәнең 18.2 статьясында каралган анкета;

4 пунктта «Мәгълүматлар» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга;

34 статьяның  11) пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

11.1 пункты белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«11.1) дәүләт сереннән торган мәгълүматларга, билгеләнгән формада рөхсәт рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров